РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru

2019 елның 12 нче августы 283№

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

**2019 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында Карар кабул итү өчен гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, 2007 нче елның 13 нче июлендәге 31-ЗРТ номерлы "Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" Республикасы Законы нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.2019 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану максатларында гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган кеременең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен(1 нче кушымта) расларга.

2.Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 нче елның 17 нче июнендәге 233 номерлы “2017 елга салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында” карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының авыл җирлегендә яшь гаиләләр һәм яшь белгечләр өчен торак төзелешен субсидияләү программасын үтәү бүлегенә әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда кулланырга.

5. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга(//htth:pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карарның үтәлешен ТР Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының яшь гаиләләр һәм яшь белгечләр өчен торак төзелешен субсидияләү программасын үтәү бүлеге башлыгына контрольдә тотуны йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Йосыпов И.В.